УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

«03» март, 2021 ел № 14

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль

законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Идарәнең хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә:

2.1. Идарәнең Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

2.2. Эштән киткәндә Идарәнең Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезләмәләрен аңлатырга.

2.3. Әлеге боерыкны, билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

2.4. Әлеге боерык күчермәсен Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2017 елның 12 октябрендәге 65 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Идарә җитәкчесе** **Г.Р. Нигъмәтуллина**

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
ГХАТ идарәсенең
2021 елның «03» марты
14 номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе җитәкчесе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

хокук һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесе;

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлеге җитәкчесе;

бухгалтерлык исәбе һәм эшчәнлекне тәэмин итү секторы мөдире.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

хокук һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (2 берәмлек);

хокук һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

контроль һәм методик эш секторының әйдәп баручы консультанты (2 берәмлек);

оештыру эшләре һәм эшчәнлек башкару секторының әйдәп баручы консультанты.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

бухгалтерлык исәбе һәм эшчәнлекне тәэмин итү секторының әйдәп баручы белгече.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

оештыру эшләре һәм эшчәнлек башкару секторының 1 разрядлы белгече.